Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп гомумбелем бирү мәктәбе

№6, 2015 ел февраль

# КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ



**«Кешенең матурлыгы эчке матурлыкта чагыла” Ә.Еники**

**Кеше кайчан матур була?**
**Кеше матур шул вакыт:**
**Иле өчен, халкы өчен**
**Яшәгәндә җан атып.**
**Заманының авырлыгын**
**Җилкәсендә алганда,**
**Олы данга ирешеп тә,**
**Кече булып калганда.**
**Олы җан булып калганга,**
**Олы җанлы булганда.**

**Ренат Харис**

### *Мәктәп яңалыклары*

Февраль ае кыска булса да, чараларга бай булды. Әлеге ай мәктәбебездә хәрби – патриотик айлык буларак билгеләп үтелде. 5 февраль көнне тарих укытучысы Рәхмәтуллина Айгөл Әбүзәр кызы җитәкчелегендә, IX сыйныф укучысы Даутова Дилбәр, балалар иҗат үзәгендә булып үткән «Родные лица победы» дип исемләнгән конкурста катнашып кайттылар. Дилбәр якташыбыз Морат Мостафинның батырлыгына, тормыш юлына багышланган электрон презентация күрсәтте.

Укытучылар коллективы 6 февральдә авыл җыенында катнашты. Җыенда мәктәбебез директоры Найлә Нуретдин кызы Әхмәтҗанова мәктәпнең еллык эшчәнлегенә хисап тотты.

11 февраль көнне мәктәбебездә “Сәламәт яшәү рәвеше”дигән темага әти-әниләр җыелышы булып үтте.

15 февраль көнне “Созвездие—Йолдызлык 2015” Республика бәйгесендә “Мы просто дети” һәм “Спецназ” дигән биюләре белән катнашып безнең укучыларыбыз II турга үттеләр. Котлыйбыз!

19 февраль көнне башлангыч сыйныф укытучысы Газизова Рушания Хатыйп кызы җитәкчелегендә “Ягез әле, егетләр!” бәйгесе үткәрелде. Бәйгедә “Җитезләр” һәм “Кыюлар” командалары ярышты. “Кыюлар” командасы җиңүче дип табылды.

21 февраль - Халыкара туган тел көне буларак, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Закирова Гөлназ Миннехан кызы “Җыр булырлык сүзләр биргән, Туган телем, рәхмәт сиңа!” дип исемләнгән ачык чара үткәрде. Чарада Туган тел турында видеоязмалар күрсәтелде, укучылар тарафыннан туган тел турында җырлар башкарылды, тел турында шигырьләр сөйләнде.

“23 февраль – Ватанны саклаучылар көне” билгеләп үтелде. Бу бәйрәмгә укучыларның әтиләре, Афганчылар, Чечняда, Чернобыльдә хезмәт иткәннәр, хезмәт ветераннары, мәртәбәле кунаклар чакырылды. Бәйрәмгә чакырылган кунаклар үзләре турында сөйләделәр, истәлекләре белән уртаклаштылар. Сөйләүләр укучыларның бию һәм җырлары белән аралашып алып барылды. Соңыннан әтиләр һәм килгән кунаклар бәйрәм табынына чакырылды, бүләкләр тапшырылды.

Сугыш чоры җырларына, халкыбызның Бөек Ватан сугышындагы батырлыгын сүрәтләгән рәсемнәргә һәм иншаларга конкурс оештырылды.

Укытучыларның һөнәри осталыкларын барлау максатыннан үткәрелүче “Ел укытучысы – 2015” бәйгесендә безнең мәктәптән тарих һәм җәмгыять белеме укы- тучысы Айгөл Әбүзәровна Рахматуллина катнашты. Алан урта мәктәбенең VI сыйныф укучыларына җәмгыять белеменнән “Идеал һәм кыйммәтләр” дигән темага дәрес күрсәтте. Тәбрик итәбез! Уңышлар телибез!

**Фото калейдоскоп**



# 2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

ГОД ЛИТЕРАТУРЫ В РОССИИ 2015

*12 июня 2014 года Президент России Владимир Путин подписал Указ «О проведении в Российской Федерации Года литературы».*

Основная цель проведения «тематического» года - привлечение внимания общества к литературе и чтению.

Глава Федерального агентства по печати и массовым коммуникациям Михаил Сеславинский отметил, что в планах Года литературы масштабные и интересные мероприятия, среди которых:

- международный писательский форум -«Литературная Евразия»,
- проект «Литературная карта России»,
- «Библионочь - 2015»,
- проекты «Книги в больницы» и «Лето с книгой: дни чтения в летних лагерях»,
- творческие встречи писателей с читателями в библиотеках и книжных магазинах Москвы и регионов РФ,
- пилотный проект «Всемирный День Книги»,
- конкурс «Литературная столица России» и др.

***"Чтение—вот лучшее учение"***

Человек, любящий и умеющий читать, - счастливый человек" (К.Паустовский)

Почему компьютер, телевизор вытесняет сейчас книгу? Да потому, что они заставляют нас не торопясь зайти и посмотреть ту информацию или передачу, которая нужна тебе. Телевизор отвлекает от забот, он вам диктует, что смотреть, как смотреть.

Но постарайтесь выбрать книгу по своему вкусу, отвлекитесь на время от всего на свете, сядьте скнигой поудобнее—и вы поймете, что есть много книг, без которыз нельзя жить, которые важнее и интереснее, чем информация в компьютере.

Я не говорю: перестаньте сидеть в компьтере. Но я говорю тратьте свое время на то, что достойно этой траты. Смотрите с выбором. Читайте больше и читайте с величайшим выбором. Определите свой выбор и никому не подчиняйтесь в выборе чтения, кроме той силы, которую приобрела в истории человеческой культуры книга классическая...

Э. Эйнштейн, сказав однажды, что наибольшее наслаждение испытал не тогда, когда открыл теорию относительности, а когда прочитал "Преступление и наказание" Достоевского.

Я согласна со словами Д.Дидро, "люди перестают мыслить, когда перестают читать". Я скажу больше , не только мыслить—перестают духовно расти, теряют способность быть душевно богатыми, если перастают читать классическую литературу.

Перефразируя пословицу "Скажи мне, что ты читаешь, и я скажу кто ты". И я понимаю, что люди (а исключением некоторых), не скажут мне,что читали (перечитывали) Толстого, Пушкина, А.Гайдара. А ведь человеку свойственно стремиться к осмыслению мира, жизни и собственного Я. Образы—это пища для глаз, книга—пища для ума. И в этом смысле книга незаменима.

Во всем, что сделано и делается человеком, в каждой вещи заключена его душа, всего больше этой чистой и благородной души в науке, в искусстве, всего красноречивее и понятнее говорит она в книгах.

Арсланова И. М., учитель русского языка и литературы

***«...по статистике, российские граждане... отводят чтению книг в среднем лишь девять минут в сутки, причем отмечается тенденция к сокращению и этих девяти минут»***

***В. В. Путин***

Китап – киңәшчең синең,

Дустың, ярдәмчең синең,

Ул хөрмәткә бик хаклы,

Кадерлә син китапны.

Көн дә укы син аны:

Китап-якын дустың ул,

Синең сорауларыңа

Җавап биреп торсын ул!

Р.Фәхреддин: "Китап уку кешенең йөзенә нур, күңеленә шатлык китерер, шуның өчен зиһен хезмәте белән шөгыльләнүчеләр ни кадәр арык булсалар да акыллары симез, ә йөзләре мәхәббәтле булыр ".

***"Китап, китап минем кулымда, сердәшем ул барыр юлымда", - дигән С.Хәким.***

"Китап укып елый алганнарның,

Күңелендә булмый каралык..."

***Татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай "Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем була минем юл күрсәтүче йолдызым", - дип язып калдырган.***

Без мөхтәрәм укытучыларыбызга берничә сорау белән мәрәҗәгать иттек: к***итаплар юл күрсәтүче йолдыз кебек, яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга, уйланырга, нәтиҗә ясарга өйрәтәләр. Сезнең китапларга карашыгыз нинди? Сезнең өчен китап нәрсә ул?***

***Найлә Нуретдиновна:*** Китап - алыштыргысыз дус. Аны укыганда, язучы белән сөйләшәсең кебек тоела. Ә иң мөһиме, китаплар безнең үзебезне ачарга ярдәм итә, дөньяга карашны үзгәртә. Безнең тылсымлы, ягымлы дустыбыз буларак, китап безне гаҗәеп һәм мавыктыргыч дөньяга алып керә, җир һәм космос турында, туган илебездәге һәм башка илдәге балалар тормышы турында сөйли, күренекле кешеләр белән таныштыра. Китап укыган саен без акыллырак, көчлерәк, ягымлырак була барабыз.

***Гөлнур Әхмәтзәкиевна:*** Кечкенәдән китап укырга яраттым. Яхшы китап кешене уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Китап укуны бернәрсә дә, хәтта яхшы спектакль яки кино карау да алыштыра алмый. Китап - минем өчен белемнәрне үстерү, шул ук вакытта ял итү дә.

***Хәдичә Нургалиевна:*** Китапларга карашым бик яхшы. Минем өчен китап – белем учагын көйрәтүче, өйрәтүче, остаз, киңәшче, иптәш. Китап — белем чишмәсе ул. Китап кешедә күркәм сыйфатлар тәрбияли, дөньяны танып белергә булыша. Китаптан башка белем юк.

***Гөлназ Миннехановна:*** Китапларда халык хәтере, борынгы бабаларыбызның үткәне язылган. "Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк",- дигән Шиһабеддин Мәрҗани. Чыннан да, бу сүзләрдә хаклык бар. Халкыбызның үткәнен китаплардан укып беләбез бит. Шуңа да мин яшь буынның китап укуын, гыйлем җыюын телим. Үткәнебезгә, киләчәгебезгә битараф булмасак иде!

***Тәслимә Миннуровна:*** Китап — ул белем чишмәсе. Без китаптан бөтен сорауларга җавап табабыз. Китап күп укыган кеше рухи яктан бай, белемле, тәрбияле була. Мин, хәтта, укыган китапларымның санын да әйтә алмыйм. Китап бик күп нәрсәләргә өйрәтә ул. Яратыгыз китапны.

Укучыларга да шул ук сорауны бирдек.

***Сафиуллина Илүзә (9 сыйныф):*** Әйе, чыннан да, китап тәрбияче кебек, безне яхшылыкны ямалыктан аерырга, тәртипле булырга өйрәтә. Китапларның төрлесе була: әкиятләр, табышмаклар, мәкаләләр һ.б. Шулай ук кечкенә балалар өчен рәсемнәр төшерелгән китаплар да бар. Китап безне яшәргә өйрәтә дип әйтсәк тә, дөрес булыр. Китап күп укыган кеше киңәшләрне дә дөрес бирәдер. Кешеләр китапаларны күбрәк укысалар, бәлки, белемле, тәртипле кешеләр дә арабызда ешрак очрар иде. Шуңа күрә, дуслар, әйдәгез интернетны беразга гына онытып, китаплар укыйк!

***Даутова Гөлшат (6 сыйныф):*** Минемчә, китап — белем чишмәсе. Анда бик күп акыл хәзинәсе тупланган.

***Шәйхетдинов Фирдүс (7 сыйныф):*** Минем өчен китаплар белем алу әсбабы. Китаптан төрле мәгълүмәтләр аласың. Китапны яхшы тотарга кирәк, ертмаска, бөкләмәскә, өстенә язмаска. Китапны тышлап кына йортергә, ертылса, ябыштырырга кирәк.

***Закиров Фәннур (7 сыйныф):*** Китап — кешене тәрбияләргә сәләтле. Китап минем өчен ул белем чишмәсе.

***Аскаров Данис (9 сыйныф):*** Китап — ул минем өчен алтын кебек. Аны пычратмыйча, ертмыйча, чиста итеп сакларга кирәк.

***Даутова Дилбәр (9 сыйныф):*** Китапны яратырга, хөрмәт итәргә кирәк. Мин үзем китап укырга яратам. Шуңа күрә дә минем өемдә кечкенә генә китапханә бар. Мин ул китапларны кадерләп саклыйм, чистартып торам. Мин үземнең шундый хәзинәм булганга шатланам, горурланам. Мин кулыма китап алам. Китапны ачуга бер тылсымлы юл эченә кереп китәм кебек. Яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга, уйланырга, нәтиҗә ясарга өйрәнәм. Шуңа күрә мин калганнарга мондый киңәш бирәм. Китапны укыгыз, яратыгыз, хөрмәт итегез, бары тик аннан соң гына бәхетле була алачаксыз.

***Шәнгәрәев Рушан (9сыйныф):*** Китапны саклап кына тотарга кирәк.

***Шаһиева Фәридә (5 сыйныф):*** Минем өчен китап белем чишмәсе. Син аннан яңа мәгълүматләр аласың. Мин барлык китапларны да яратам. Хәрбер китапны сакларга, аны тышлап кына йөртергә кирәк.

# 23 ФЕВРАЛЬ—ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ




**Кадерле әтиләребез, ир – ат укытучыларбыз, мәктәбебез малайлары!**

**Сезне ихлас күңелебездән**

**23 февраль – Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз!**

**Сезгә озын гомер, саулык – сәламәтлек, ак бәхетләр, күп шатлыклар, укуыгызда һәм эшегездә зур уңышлар телибез.**

Ватан ул бик гомумиләштерелгән сүз. Бу сүзне әйткәндә без туган җирне генә түгел, әти-әнине дә, балаларны да, гаиләне дә күз алдында тотабыз. Ә Ватанны саклаучылар дип сезгә, кадерле ир-атларыбызга, дәшәбез.

Әйе, тормышның иң кадерлеләре—туган җир, ата-ана, бала, гаилә иминлеге күз белән караганда тар гына тоелган йөк сезнең җилкәләрегезгә салынган. Нинди зур җаваплылык! Рәхмәт, сезгә, шул җаваплылыкны үз өстегездә тоеп, ватанны саклаучылар сафында булганыгыз өчен. Рәхмәт сезгә безнең күңелләрдә ышаныч һәм тынычлык уятканыгыз өчен. Беркайчан да авырмагыз, сау-сәламәт булыгыз.

Ватанны саклаучылар көне белән барыгызны да, ихластан сезне тәбриклибез!

## *ЕГЕТЛӘР армиядә сынала*



*23 февраль—Ватанны саклаучылар көнен без барыбыз да көтеп алабыз. Абыйлар, әтиләр, бабайлар бәйрәме ул. Алар саклаган безнең Туган илебезне. Бөек Ватан сугышы кырларында, Совет Армиясе сафларында... Бигрәк тә безнең малайларыбыз, егетләребез өчен истәлекле көн бу. Чөнки иртәгә Ватаныбызны алар саклаячак. Солдат булып, кулларына корал тотып. Аның өчен алар иң элек Туган илебезнең патриотлары булып үсәргә тиеш.*

*Элек армиядә хезмәт итеп кайткан егетләрнең дәрәҗәсе бер баскыч югары торган. Алар кызлар арасында да почетта йөргән. Хәзер, киресенчә, төрле сәбәп табып, армиягә бармый калганнарга игътибар күп, хөрмәт зур. Янәсе, армия кешенең психикасын боза, нервасын какшата, анда булдыксызлар гына бара дип саныйлар. Хәрби хезмәттән качып калу өчен исә егетләр нинди генә сәбәп тапмый, чиргә дә сыбыша, психик авырулар хәстаханәсендә дә "дәваланым" чыгалар.*

*Безнең мәктәбебезнең 2010-2011 нче елгы чыгарылыш сыйныф укучысы Гыйльметдинов Азат бүгенге көндә Хабаровск краенда Ерак Көнчыгыш хәрби округында хезмәт итә. Ул Ватан алдындагы бурычын үтәргә үзе теләп китте. "Армиядә хезмәт итү һәр егет өчен кирәк. Ул әле яңа гына әни итәге астыннан чыккан егетләрне чын ир-ат ясый, мөстәкыйльлеккә, карар кабул итәргә өйрәтә",-дип яза бүген Азат үзенең хатларында.*

*Солдат хезмәтеңне матур үтәп, исән –имин әйләнеп кайт, Азат!*

***Серапионов Арслан, 7 сыйныф***

***

*Әтиемне бик яратам,*
*Көтеп алам һәр көнне.*
*Эштән һәр көн ашыга-ашыга*
*Сагынып кайта безне.*

*Ничек инде соңга калсын,*
*Энекәш бит бар минем.*
*Һәммәбез дә көтеп тора*
*Иркәләвен әтинең.*

*Без әтинең ике йолдызы,*
*Аны бик яратабыз.*
*Әтиебез исән булса,*
*Без бәхетле булырбыз.*

***Мөхәммәдиева С., 3 сыйныф***

***

*Әтиемне бик яратам,*
*Исеме аның Рушан.*
*Ул янымда булган чакта*
*Булам мин бик шат.*

*Әти белән эшләгәндә,*
*Рәхәт була күңелгә.*
*Әтиемә рәхмәтле мин*
*Шуны әйтәмен сезгә.*

***Рахматуллина Диана, 2 сыйныф***

### *Солдат абый*

*Аяз бүген күгебез,*
*Солдат абый сакта торгандa.*
*Тыныч бүген безнең көнебез*
*Батыр халкым минем булганга.*
*Солдат абый сакта торса*
*гына*
*Тыныч була безнең балачак.*
*Горур, батыр халкым булса*
*гына,*
*Һәр туар таң аяз булачак*

***Гараев Гадел, 4 сыйныф***

### *Әтигә охшарга тырышам!*

*Минем әтием Дамир исемле, ул шофер булып эшли. Ул үз эшенең чын остасы. Әтием турында авылдашлары "алтын куллы егет" диләр. Чөнки нинди генә эшкә тотынса да, эшен җиренә җиткерә белә. Мине дә хезмәт сөеп үсәргә өйрәтә. "Кечкенәдән өйрәнсәң, үскәч җиңел була ул, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз диләр бит", - дип елмаеп куя.*

*Әле дүртенче сыйныфта гына укысам да, инде машинаның бөтен төзелешен беләм, хәтта аның белән идарә итәргә дә өйрәндем. Рәхмәт сиңа, әтием! Авырмыйча озак яшәсәң иде.*

***Закиров Данияр, 4 сыйныф***

### *Изге бурыч*

*Килеп җитте февраль дә,*
*Тиздән җитә зур бәйрәм.*
*Ватанны саклаучыларга*
*Бездән ялкынлы сәлам.*
*Ватаныбызны саклау-*
*Егетләрнең бурычы.*
*Яшьтән шөгыльләнеп кенә*
*Арта аларның көче.*
*Һәрбер егет яшьтән үк*
*Спорт белән дус булсын,*
*Көчләре ташып торсын,*
*Беләкләре нык булсын.*
*Туган якны, Ватанны*
*Сез сакламый, кем саклар?*
*Әнкәйләрнең, барыбызның*
*Өметләрен кем аклар?*

***Шайхутдинов Фирдүс, 7 сыйныф***

# ХАЛКЫМНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ



**Әтием, Галимҗанов Миңсуәр Әбелгаз улы, 1986 елда Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән вакытта, Чернобыль катастрофасын ликвидацияләүдә катнашкан. Шул чордагы фидакарь хезмәте өчен 2011 елда II дәрәҗәдәге "За заслуги перед Отечеством" ордены медале белән һәм "В память о ликвидации катастрофы на ЧАЭС" медале белән бүләкләнде.**







"Теләче" газетасы, 2011 ел, 27 июль, №58 (965)



**Әтием армия хезмәтенә 1985 елның маенда алына. Хәрби хезмәтне ул һава гаскәрлерендә, Украинаның Днепропетровск шәһәре янындагы Гвардия бистәсендә хәрби частьтә башлый. Аңарчы Биектау районының Чебокса авылындагы профессиональ-техник училищеда шоферлыкка укый. Армиядә дә шофер сыйфатында хезмәт куя. Нәкъ бер ел хезмәт иткәннән соң, ягъни егерме алтысында, Чернобыльдә фаҗига була. "Егерме тугызында анда идек. Гел рейста балганлыктан, безне җибәрделәр. Башта радиацияле зонадан җирле халыкны ташыдык. Утыз чакрым ераклыкта кереп йөри идек, - дип сөйли минем әтием. – Зарарлы зонага көнгә ике генә тапкыр керергә рөхсәт ителә иде, без үз ризалыгыбыз белән дүртәр рейс ясадык. Яхшымы-яманмы, безне совет чорында ватанпәрвәләр итеп тәрбияләделәр. Анда без нәкъ бер ай булдык," - дип дәвам итә әтием. Чернобыль атом станциясен ликвидацияләүдә катнашкан хезмәттәшләрен еш искә ала: «Ямбулаттан Фәннүр Галиев, Иске Җөридән Рәфит Әминов белән бергә хезмәт иттек. Бер савыттан ашап, янәшә койкада йокладык. Армияда да, авылга кайткач та дус булдык. Кызганыч, икесе дә мәрхүмнәр инде».**

**Әтиемә нык сәләмәтлек, әнием белән озын-озак яшәүләрен телим.**

***Галимҗанова Лилия, КБШ студенты***

**Әфган сугышында барлыгы 620 мең солдат , офицер һәм генерал, ә Татарстаннан 9 меңнән артык сугышчы катнаша. Безнең Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенә караган авылларда исә бу сугышта 4 кеше катнашкан: *Гыйльметдинов Илсур Зәйнетдин улы, Закиров Фәнил Хәйдәр улы, Закиров Миннулла Габдулла улы, Шәяхмәтов Равил Гали улы.***



Әфган сугышы... Бу коточкыч вакыйгаларга нокта куелган 1989 нчы елның 15 нче февраль көненнән соң нәкъ 26 ел вакыт узып киткән.

Мин Әфган сугышы ветераны, әтием Закиров Фәнил Хәйдәр улы турында язмакчы булам. Аңа минем хөрмәтем зур.

Әтием, 1969 нчы елның 15 нчы мартында Саба районы Кече Кибәхуҗа авылында туа. Ул 1976 нче елда Казаклар сигезьеллык мәктәбенә укырга керә. Алар җиде кыз, ике малай укыйлар. Аны тәмамлаганнан соң, Теләче урта мәктәбендә ике ел укый, 1886 елда шоферлыкка укый. 1987 елда армиягә китә. Ул Әфганстанның Маджари Шәриф шәһәрендә хезмәт итә. 1889 нчы елның май аенда әйләнеп кайта. Хәзерге вакытта Кече Кибәхуҗа авылында яшәп, ООО "Игенче" ширкәтендә тракторчы булып эшли.

Мин әтиемне гади һәм кешелекле булып калганы өчен хөрмәт итәм. Бу сыйфатларны үземдә дә булдырырга тырышам.

Тарихта канлы һәм дәһшәтле сугыш вакыйгалары күп булган. Кайсысын гына алсаң да, һәркайсында үлем, кайгы-хәсрәт, күз яше...Тик халкымның батыр уллары беркайчан һәм беркайда да сынатмаган. Бүген без алар белән горурланабыз, аларның алларында башларыбызны иябез!

**Закиров Фәннур, VII сыйныф**



Әфган сугышы...Әлеге кангойгыч сугыштан соңгы совет солдаты чыкканга да инде 26 ел тулды. Бу вакыт эчендә бик күп үзгәрешләр булды.

Минем әтием—Шәяхметов Равил Гали улы. Ул 1965 елның 15 гыйнварында туган. 1983 елда әтием Армия сафларына алына. Ә бит солдат сугышны үзе сайламый, сугышны да ул игълан итми. Әтиемне һәм башка яшь егетләрне Әфганстанга кертәләр. Минем әтиемә әфган таулары һәм далалары аша узарга, яу кырында дары иснәргә туры килә. Әфган шәһәрләрен дошманнардан азат итү өчен әтием күп көч куйган.

Бу сугыш безнең халык өчен 15 меңгә якын кургаш табут, 50 мең яралы, 312 хәбәрсез югалган солдат рәвешендә әйләнеп кайтты. Алар арасында безнең якташларыбыз Миңнегали Ногманов, Илшат Хәйруллин да бар.



**Шәяхмәтова Сөмбел, V сыйныф**

# ХӘРӘКӘТТӘ—БӘРӘКӘТ

Быстрее. Выше. Сильнее.

IV СТУПЕНЬ
(юноши и девушки 7 - 9 классов, 13 - 15 лет)

**1. Виды испытаний (тесты) и нормы**

| № п/п | Виды испытаний (тесты) | Мальчики | | | Девочки | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Бронзовый знак | Серебряный знак | Золотой знак | Бронзовый знак | Серебряный знак | Золотой знак |
| Обязательные испытания (тесты) | | | | | | | |
| 1. | Бег на 60 м (сек.) | 10,0 | 9,7 | 8,7 | 10,9 | 10,6 | 9,6 |
| 2. | Бег на 2 км (мин., сек.) | 9.55 | 9.30 | 9.00 | 12.10 | 11.40 | 11.00 |
| | или на 3 км | Без учета времени | Без учета времени | Без учета времени | - | - | - |
| 3. | Прыжок в длину с разбега (см) | 330 | 350 | 390 | 280 | 290 | 330 |
| | или прыжок в длину с места толчком двумя ногами (см) | 175 | 185 | 200 | 150 | 155 | 175 |
| 4. | Подтягивание из виса на высокой перекладине (кол-во раз) | 4 | 6 | 10 | - | - | - |
| | или подтягивание из виса лежа на низкой перекладине (кол-во раз) | - | - | - | 9 | 11 | 18 |
| | или сгибание и разгибание рук в упоре лежа на полу (кол-во раз) | - | - | - | 7 | 9 | 15 |
| 5. | Поднимание туловища из положения лежа на спине (кол-во раз за 1 мин.) | 30 | 36 | 47 | 25 | 30 | 40 |
| 6. | Наклон вперед из положения стоя с прямыми ногами на полу | Достать пол пальцами | Достать пол пальцами | Достать пол ладонями | Достать пол пальцами | Достать пол пальцами | Достать пол ладонями |
| Испытания (тесты) по выбору: | | | | | | | |
| 7. | Метание мяча весом 150 г (м) | 30 | 35 | 40 | 18 | 21 | 26 |
| 8. | Бег на лыжах на 3 км (мин., сек.) | 18.45 | 17.45 | 16.30 | 22.30 | 21.30 | 19.30 |
| | или на 5 км (мин., сек.) | 28.00 | 27.15 | 26.00 | - | - | - |
| | или кросс на 3 км по пересеченной местности* | Без учета времени | Без учета времени | Без учета времени | Без учета времени | Без учета времени | Без учета времени |
| 9. | Плавание на 50 м (мин., сек.) | Без учета времени | Без учета времени | 0.43 | Без учета времени | Без учета времени | 1.05 |
| 10. | Стрельба из пневматической винтовки из положения сидя или стоя с опорой локтей о стол или стойку, дистанция - 10 м (очки) | 15 | 20 | 25 | 15 | 20 | 25 |
| | или из электронного оружия из положения сидя или стоя с опорой локтей о стол или стойку, дистанция - 10 м (очки) | 18 | 25 | 30 | 18 | 25 | 30 |
| 11. | Туристский поход с проверкой туристских навыков | В соответствии с возрастными требованиями | | | | | |
| Кол-во видов испытаний (тестов) в возрастной группе | | 11 | 11 | 11 | 11 | 11 | 11 |
| Кол-во видов испытаний (тестов), которые необходимо выполнить для получения знака отличия Комплекса** | | 6 | 7 | 8 | 6 | 7 | 8 |

*Для бесснежных районов страны.
** При выполнении нормативов для получения знаков отличия Комплекса обязательны испытания (тесты) на силу, быстроту, гибкость и выносливость.

2015 ел илебездә йөрәк—кан тамырлары авыруларына каршы көрәш елы дип игълан ителде. Ә аларны булдырмый калуның төп нигезе – хәрәкәт, дигән фикердә табиблар.

Белгечләр көненә 5 километр җәяү йөрергә кирәк, дип киңәш ителәр. Министр Гадел Вафин җитәкчелегендә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы хезмәткәрләре әлеге фикерне үз мисалларында расларга булдылар һәм парктагы юлларны кардан чистарту өчен өмәгә чыктылар.




### *Физкультсәлам*

Республикада ГТО нормативларын беренче булып Президентыбыз Рөстәм Миннеханов тапшыра башлады. Президент яшьләр белән бер очрашу вакытында 25 тапкыр отжимание ясады һәм, пневматик винтовкадан атып, 50 мөмкинлектән 46 очко җыйды.

ГТО нәрсә икәнен белмәгән тулы бер буын үсеп җитте. ГТО нәрсә ул? Шул сорау белән без физкультура укытучысы Даутов Ришат Гомәровичка мөрәҗәгать иттек.

- Соңгы вакытта Русия хөкүмәте ил халкының сәламәтлеге хакында зурдан кубып борчыла һәм кайгырта башлады. Кайчандыр бөтен ил халкын сәламәт яшәү рәвешендә өндәгән һәм күпмедер дәрәҗәдә үз бурычын үтәгән ГТО комплексын кире кайтару–моның бер ачык мисалы. СССРда 1931 елда гамәлгә кертелеп, 90 нчы еллар башына кадәр, ягъни 60 ел яшәгән хәрәкәт, чыннан да массакүләм булган. Хәзерге вакытта ГТО илнең 12 төбәгендә (шул исәптән Татарстанда да) сынау үтә. Димәк, яңа кагыйдәләр шул сынау нәтиҗәләреннән чыгып төзеләчәк һәм тагын бер елдан бөтен ил буенча гамәлгә кертеләчәк.

1931 елда барлыкка килгән ГТО (Готов к труду и обороне) комплексы торабара берничә үзгәреш кичергән. Иң соңгы үзгәрешләр 1972 елда булган. Ул чорда ГТО нормативларын 10 яшьтән 60 яшькә кадәрле кешеләр тапшырган. Яшь аермаларына карап, ул 5 баскычка бүленгән.

10-13 яшьлекләр өчен беренче баскыч "Кыюлар һәм житезләр" ("Смелые и ловкие") дип атала. 14-15 яшьлекләрне исә "Спорт алмашы" ("Спортивная смена") берләштергән. 16-18 яшьлекләр өчен нормативлар "Көч һәм батырлык" ("Сила и мужество") дип юкка гына аталмагандыр. Чөнки, армиягә егетләрне нәкъ 18 яше тулгач алалар. "Физик камиллек" ("Физическое совершенство") баскычына 19 яшьтән 34 яшькә кадәргеләр карый. 35 яшьтән 60 кача булганнар "Күңел күтәренкелеге һәм сәламәтлек" ("Бодрость и здоровье") баскычы буенча нормативлар тапшырганнар. Ул үз эченә төрле дистанцияләргә йөгерү, ераклыкка һәм биеклеккә сикерү, чаңгыда узышу, мылтыктан, ядрә һәм граната ату һәм башка төрләрне ала.

- Ә бүгенге ГТО элеккесеннән нилəр белән аерыла соң?

- Иң беренче чиратта билгеләрнең (значокларның) саны арту белән. Әгәр элек норматив тапшыручыларга алтын һәм көмеш значоклар гына бирсәләр, хәзер аларга бронза значок та өстәлә. Нормативлар да үзгәргән. Әйтик, совет чорындагы исемлектән велосипедта һәм тимераякта узышу, канат буйлап өскә үрмәләү, ядрә этәрү һәм граната ыргыту төшеп калган. Элеккеге кебек кече калибры мылтыктан түгел, ә бала-чагалар тирда атып уйный торган пневматик мылтыктан ("воздушка") атачакбыз.

- ГТО яңалыклары белән таныштыруыгыз белән сезгә зур рәхмәт, Ришат Гомәрович. Безгә дә алардан калышмаска кирәк.



### *Футболдагы кызыклы хәлләр*

Мин, Аскаров Данис футбол уйнарга, телевизордан карарга яратам. Интернеттан футбол яналыклары белән танышып барам. Сезне дә андагы кызыклы хәлләр белән таныштырасым килә.

***

Көндәшнең капкасына тупны 11 метрлы ерактан тибү Ирландиянең футбол кагыйдәләре экспорты Джон Пенальти хөрмәтенә аталган икән. Ул 1891 елда тупас уен өчен шундый тибү билгеләргә тәкъдим иткән.

***

1978 елда Греция беренчелегендә «Этникос» командасы «ПАОК»ны кабул иткән. Исәпне ачып, кунаклар запас уенчылар утыручы эскәмиягә шатлык уртаклышырга йөгергәннәр. Алар дөньяларын онытып, шулкадәр нык сөенешкәннәр ки, хәтта судьяның уен башлануын белгертеп сызгыртуын да ишетмәгәннәр. "Этникос" футболчылары көндәшләр уйнамый торудан файдаланып, шундук, исәпне тигезләп куйган.

***

Томан — Англия футболының кан дошманы. Анда еш кына бөтен кыр һәм трибуналар шуның белән каплана да берни дә рәтләп күренми. Бер шундый уен 3:3 исәбе белән тәмамлагач, Джордж Одц исемле уенчы: "Мин биш гол кертқәнемне төгәл хәтерлим, ләкин кайсы капкага икәнен генә белмим", - дигән. Моннан тыш, уен беткәч, судьялар команда өчен 18әр футболчы уйнаганын белеп шаккаткан.

***Сәхифәне Аскаров Данис әзерләде.***

# БӨЕК ҖИҢҮГӘ—70 ЕЛ




***Хезмәт һәм тыл ветераны Кәлимуллина Нәкыя Галимәрдән кызы белән үткәрелгән әңгәмәдән өзекне сезгә тәкъдим итәбез.***

Кәлимуллина Нәкыя Галимәрдән кызы 1931 елның 2 нче августында Теләче районы Казаклар авылында туган.

Сугыш башланганда, ана 10 яшь була. Ул III сыйныфны тәмамлап, IV сыйныфка күчтем дип йөргән көннәрдә сугыш башлана.

Нәкыя апа Кәлимуллина хәтирәләрен күз яшьләре аша искә төшерде:

- Сугыш афәте яу кырындагыларга гына түгел, тылда калучыларга да зур авырлыклар китерде. Без, 10 яшьлек балалар, урак уручыларга көлтә бәйләштек, башак җыйдык, "Коммунар" комбайныннан салам тартып төшереп, аны җыйдык. Хәтеремдә бигрәк тә үзебезнең М.Вахитов исемендәге колхозның яшелчә бакчасында яшелчәләргә Макса елгасыннан су сибүләр, чүп утаулар калган.

Казаклар мәктәбенең ярдәмче хуҗалыгында сыйныфташларым белән ярыша-ярыша эшләп йөргәннәрем дә бүгенгедәй хәтеремдә.

Язгы чорда Максабаш авылыннан симәнә ташуда катнаштым.

Мәктәпне тәмамлагач, Олы Кибәхуҗа авылындагы "Волга" артелендә хисапчы булып эшли башладым. Аннары Казаклар сельпосында һәм Теләче райпосында 50 ел бухгалтер булып эшләп, лаеклы ялга чыктым.



Мәктәбебездә тимурчылык эше дәвам итә. Сез әлеге фотосүрәттә Александр Матросов исемендәге тимурчылык отряды тыл ветераны Закирова Сәгүрә апаның өй каршын карлардан арындырган вакытын күрәсез

***Бөек Ватан сугышына—70 ел. Иҗади эшләр конкурсы дәвам итә. Сезнең игътибарыгызга Гыйльметдинова Ләйләнең иншасын тәгъдим итәбез.***

### *Ул көннәрне чагылдырган көзге*

***Безнең өйдә бәллүр савытлар тулы матур сервантта иске бер көзге тора. Ул инде каралып, искереп беткән, күгәрә дә башлаган. Ләкин ул өебездәге иң кадерле әйбер.***

***Аның үз тарихы бар. 1941 елның декабрендә, коточкыч салкын көннәрдә, Махруй әбиемне (ул чакта япь-яшь кыз) Арча станциясе янына, башка бик күп кешеләр белән бергә окоп казырга җибәрәләр. Монда Ленинград шәһәреннән килгән яшьтәшләре дә була. Чатнама салкын суыкта ул аларга оекбаш та, бияләй дә биреп тора. Коточкыч авыр физик эш тәмамлана, окоп әзер була. Дүрт кыз, авылларына кайтырга дип, җәяү юлга чыгалар. Станция кырыендагы кибеттән бер абзыйның көзге алып чыгып килүен күрәләр. Кызлар барлы-юклы акчаларын җыеп, һәрберсе көзге сатып ала, чөнки авылларында шундый зур матур көзгеләр беркемдә дә булмый. Бармаклары тишелеп беткән бияләйләре белән утыз градус суыкта кызлар көзгеләрен кочаклап кайталар. Арып-талып, юлдагы бер урыс апасына төн кунарга керәләр. Апа бу кызларны күргәч, елап җибәрә: "Кызлар, сугыш бара бит! Фашист килә! Менә ике улымның үлгән хәбәре килде..."***

***Кызлар апаны мөмкин кадәр юаталар. "Җиңү барыбер киләчәк", - диләр.***

***...Әбием алып кайткан көзгене карарга бөтен күрше-күлән җыела. Җирдә әле матурлыкка табынган кызлар күңеле барлыгын искә төшереп, яшьлек һәм сөю билгесенә әйләнә бу көзге.***

***...1941 елның июнендә үк әбием үзенең яраткан егетен, бабам Хәсән Шәнгәрәевне фронтка озаткан була. Киткәндә ул бабама матур итеп чигелгән кулъяулык биреп җибәрә. Үзенә дә шундый ук кулъяулыкны калдыра. Аннан килгән хатларны ул шушы көзге алдында саклый, серләрен, сагынуын шушы көзгегә сөйли. Чигелгән кулъяулык та сугыш елларында, көзге алдында, әбием белән берге бабамны көтә. 1945 елның маена бу көзге инде бик күп хатлар туплый. Һәм тиздән, сугышта ике тапкыр яраланган, Хәсән бабам җиңүче булып туган авылына кайта.***

***Бабам, сугыштан исән-имин кайткач, бик күп алмагачлар утырта. "Мин аларны сугышта һәлак булып калган иптәшләремә багышлап утырттым", - дия торган булган ул балаларына. Ул Ленинград обронасы, Курск дугасындагы сугышлар, Германиядәге каты бәрелешләр турындагы истәлекләрен сөйләргә яраткан. Кызганычка каршы, бабам сугышта алган яраларыннан вафат була. 9 нчы майда без аның каберенә килеп, чәчәкләр куябыз, бабабыз алдында баш иябез.***

## Дети рисуют войну



















**9 сыйныф** укучысы **Сафиуллина Илүзәнең- 5 февраль,**

**6 сыйныф укучысы Рәхмәтуллина Энҗенең – 5 февраль,**

**6 сыйныф укучысы Закирова Алинәнең – 6 февраль,**

**3 сыйныф укучысы Саидова Магсуманның - 25 февраль**

***Туган көнегез белән котлап***

***Бәхет телибез сезгә, дуслар.***

***Иңнәрегезгә бары изге***

***Фәрештеләр генә кунсын!***



**Иң зур бүләгем**

**Кемне генә сокландырмас, шатландырмас,**

**Яңа гына ачылып килгән сабый теле!**

**Зур бер ачыш, табыш сыман тоела бит,**

**Аның башлап әйтер һәрбер яңа сүзе.**

**Оныгыма ана теле бүләк иттем,**

**Татарчалап: "Әти!" - диде. "Әни!"-диде.**

**Бөтерчектәй бөтерелеп биеп йөрде.**

**Оныгыма ана теле бүләк иттем,**

**Күңел түрен нурлап торыр шиңмәс гөлне-**

**Алтын, көмеш, җәүһәрләрдән кыйммәтлерәк,**

**Тукай, Такташ, Җәлилләрне биргән телне!**

**Э.Мөэминова**

# Котлыйбыз!

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп белем бирү мәктәбенең укыту-тәрбия эшләре директор урынбасары һәм география, биология укытучысы Әскарова Флүзә Гайсиновнаның 7 февральдә, тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Даутов Ришат Гөмәровичның 9 февральдә туган көннәре.**

## Хөрмәтле Флүзә Гайсиновна, Ришат Гомәрович!

**Сезне чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә сәламәтлек, хезмәт уңышлары, балалар бәхете, озын гомер телибез.**

**Халкыбыз җәүһәрләре булырдай**

**Шәхесләр бу җирдә җитәрлек.**

**Сезгә дә тумыштан бирелгән**

**Тырышлык, акыл һәм зирәклек.**

**Вөҗдан күзе белән карыйсыз Сез**

**Тормыштагы һәрбер мизгелгә.**

**Күпме изге гамәл эшне булып**

**Гомер юлыгызга сибелә.**

**Саф алтын кугәрми беркайчан,**

**Онытылмый мәңгегә изгелек.**

**Телибез бәйрәмдә зур саулык,**

**Бетмәс көч, бәхет һәм иминлек.**

## *21 ФЕВРАЛЬ—ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ*

1954 елның 21 февралендә Бангло халкы үз теленең хокукларын яклап чыккач, канлы бәрешләр вакытында 5 студент һәлак була. Шушы фаҗигале вакыйганы истә тоту йөзеннән, ЮНЕСКО халыкара оешмасы 21 февральне «Туган тел» көне дип игълан итә. Ун биш еллар элек барлыгы 7 мең тел бар дип саналса, хәзер 7 меңгә якын дип кенә әйтәләр, чөнки ел саен дөньяда уртача 10 тел югала, шул исәптән Россиядә—1 тел. Шул 7 меңгә якын тел арасында бары тик 2 мең тел укытыла, ә кайбер телләрдә бармак белән генә санарлык кеше сөйләшә. Россия Федерациясендә—150гә якын, ә Татарстанда 35 телдә сөйләшәләр, 6 телдәге мәктәпләр эшләп килә.

Россиядә 136 тел юкка чыгарга мөмкин. ЮНЕСКО юкка чыгып баручы телләр атласының яңа чыгарылышын бастырды. Атлас 1950 елдан бирле чыга. Шул вакыттан бирле дөнья халыкларның 200 теле мәңгегә югалган.

Телләр алты категориягә бүленә Безнең илдә 20 телнең хәле (мәсәлән, ***якут һәм тува***) куркыныч астында. 49 тел, шул исәптән ***удмурт һәм калмык*** телләре юкка чыгу алдында тора. Атласта күрсәтелгәнчә, ***нивх, чукот, карел*** телләре бик кыен хәлдә. ***Айн, юг, убых*** телләре элегрәк юкка чыккан инде. "Телләрнең юкка чыгуы объектив күренеш, - диләр А.С.Пушкин исемендәге Дәүләт рус теле институтында.—Теге яки бу җәмгыятьтә туган телне балаларның 30 проценты өйрәнмәсә, бу—телнең юкка чыгуының беренче билгесе.

Газетаны гамәлгә куючы: ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе администрациясе

**Баш мөхәррир:**

VII сыйныф җитәкчесе

И.М.Арсланова



Безнең адрес:

422080, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урам ,10 нчы йорт.

Белешмәләр өчен телефон: 56 – 2 – 40

e-mail: mkibiakozi40@mail.ru